**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕЛӘНЧЕ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«01» ноябрь, 2019 ел Теләнче Тамак авылы № 15

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 13 ноябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авылы Колхоз, Кызыл армия, Тукай, Кооператив урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Теләнче Тамак авылы , Кызыл армия урамы , 21а йорт янында билгеләргә.
2. 2019 елның 14 ноябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авылы Тау як, Совет, И. Шакиров, Мәктәп, Балалар бакчасы, Мәктәп тыкырыгы урамнарында, Татарстан урамынын 3-55 йортлары, үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Теләнче Тамак авылы, Татарстан урамы, 19 йортта билгеләргә.
3. 2019 елның 15 ноябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авылы Селҗхозтехника, Подстания, Хастаханә, Яшьләр, Яңа урамнарында, Татарстан урамынын 1 һәм 2 йортларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Теләнче Тамак авылы, Сельхозтехника урамы, 2 йорт янында билгеләргә.
4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Теләнче Тамак авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә

билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1. юллар ремонты.
2. Сабантуй бэйрэмен үткәрү һәм бүләкләр алу

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

8. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Назметдинов